РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Центральная, 7,д. Караталга, 422834
тел. (8-834-77)30-4-39, факс: (8-834-77) 30-4-39
ОКПО 93064642 , ОГРН 1061672003425
ИНН/КПП 1622004595/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ИСКЕ КАЗИЛЕ**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Үзәк урамы, 7, Каратал авылы, 422834,
тел(8-834-77)30-4-39. , факс: (8-834-77)30-4-39
ОКПО 93064642, ОГРН 1061672003425
ИНН/КПП 1622004595/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**29 январь 2021 ел** **№ 1**

**2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында" 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегендә № 1 Кушымта һәм № 2 кушымта нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6424,98 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» гы 2020 елның 30 январендэ кабул ителгэн 2 нчы номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14 һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге Советы Рәисе И.Х. Сәгдиев

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
Башкарма комитеты карарына
кушымта
№ 1 «29» гыйнвар 2021 ел

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән алып җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен табут һәм башка кирәк булган предметларны китереп бирү | 3850,02 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен китеру | 547,86 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2027,10 |
| **Барысы** | 6424,98 |

Кушымта № 2
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
Башкарма комитеты карарына
кушымта
№ 1 «29» гыйнвар 2021 ел

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән алып җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне каплау | 197,58 |
| 3. Җирләү җыелмасы – Кэфенлек, такта комплекты, җирләү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3652,44 |
| 4. Зиратка үлгән кешенен мәетен китерү | 547,86 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2027,10 |
| **Барысы** | 6424,98 |